КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 12 апрель г.Казань № 221

Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче риск төркемнәрендәге хезмәткә сәләтле яшьтән өлкәнрәк гражданнарга пневмококк инфекциясенә каршы вакцинация үткәрү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1640 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче риск төркемнәрендәге хезмәткә сәләтле яшьтән өлкәнрәк гражданнарга пневмококк инфекциясенә каршы вакцинация үткәрү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче риск төркемнәрендәге хезмәткә сәләтле яшьтән өлкәнрәк гражданнарның пневмокок инфекциясенә каршы вакцинация уздырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен раслау турында» 2019 ел, 15 апрель, 287 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 12 апрель, 221 нче
карары белән расланды

Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче риск төркемнәрендәге хезмәткә сәләтле яшьтән өлкәнрәк гражданнарга пневмококк инфекциясенә каршы вакцинация үткәрү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче риск төркемнәрендәге хезмәткә сәләтле яшьтән өлкәнрәк гражданнарга пневмококк инфекциясенә каршы вакцинация үткәрү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче риск төркемнәрендәге хезмәткә сәләтле яшьтән өлкәнрәк гражданнарга пневмококк инфекциясенә каршы вакцинация үткәрү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән һәм әлеге максатлар өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидия (алга таба – субсидия)(алга таба – бюджет акчасы) исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.

4. Бюджет акчасын тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, иң чик финанслау күләмнәре Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан җиткерелгәннән соң,иң чик финанслау күләмнәрен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерә.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә пневмок инфекциясенә каршы вакциналар сатып алуга дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзи (контрактның бәясе вакцина, тара, төргәкләр, маркировка, саклау, җибәрү, лицензия җыемнары кыйммәтеннән, хезмәт өчен түләү фондыннан, шулай ук ташу, иминләштерү, таможня пошлиналарын түләү, салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләр чыгымнарыннан гыйбарәт);

пневмококк инфекциясенә каршы вакциналар сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзелгән оешмаларга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) шартлары нигезендә акча күчерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда финанслашу максатларында субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап, шулай ук субсидиядән файдалану нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап урнаштыра.

8. Бюджет акчасын максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җавап бирелә.

9. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына субсидиянең файдаланылмый калган өлеше Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

---